**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　К А Р А Р

от ____________　　　ПР-260 28.11.2024　　　№ _______

«Су объектларының төбе һәм ярлары үзгәрүгә бәйле, төпне тирәнәйтү һәм башка эшләр башкарганда төптән алынган грунтны файдалану турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләр административ регламентын раслау турында» Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 15 июль 2022 ел, № ПР-140 карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында" 15.08.2022 ел, № 1415 карары нигезендә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Су объектларының төбе һәм ярлары үзгәрүгә бәйле, төпне тирәнәйтү һәм башка эшләр башкарганда төптән алынган грунтны файдалану турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләр административ регламентына түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. 3.3.2 пунктының 12 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төзелгән гарызнамәне формат-логик тикшерү орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче гарызнамәнең электрон рәвешендәге һәр кырын тутырган вакытта, бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал сорауның электрон рәвешендәге дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры сорауның электрон рәвешендәге мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.»;

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

Башкарма комитет
Җитәкчесе　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Р. А. Ильясов